СОВЕТ КЛЯУШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Первомайская, д.51, д.Пойкино, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422142

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЛӘҮШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Беренче май ур., 51 нче йорт, Пойкино авылы, Мамадыш районы, . Татарстан Республикасы,422142

тел.(факс): (85563) 3-89-193; e-mail: Kls.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

«10» гыйнвар 2025 ел. — № 1-42

Келәүш авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, Б.В.Иванов үз теләге белән отставкага китүе турында шәхси гаризасы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге Советы

к а р а р к а б у л и т т е:

1. 2025 елның 10 гыйнвар Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Келәүш авыл җирлеге башлыгы Иванов Борис Викторович үз теләге белән отставкага китүе сәбәпле вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://mamadysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Келәүш авыл җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3.Карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Утырышта рәислек итүче — Р.Х.Шайдуллин